## Таҗи Гыйззәт

(1895—1955)



Татар совет драматургиясенә нигез салучыларның берсе Таҗи Гыйззәт 1895 елның 15 сентябрендә Әгерҗе районының Баржы Умга авылында туа. Әтисе Кәлимулла агай, ишле гаиләне туйдыру өчен күп кыенлыклар кичерсә дә, балаларына белем бирергә, аларны укытырга тырышкан. Таҗи остабикәдән сабак ала, аннары янача тәртиптәге җәдит мәдрәсәсендә укый. Аның балалык һәм яшьлек еллары Иж елгасы буенда уза.


Самарадагы татар театр студиясен тәмамлаганнан соң үзенең остазы Кәрим Тинчурин җитәкчелегендәге театр труппасында Оренбургта эшләп ала. Урта Азия, Ульяновск, Алабуга, Мәскәү шәһәрләрендә төрле хезмәт вазифалары башкарганнан соң, 1929 елны Казанга кайта. Һәм шунда бөтенләйгә төпләнеп калып, 1950 елга кадәр Г. Камал исемендәге Татар дәүләт театрында хезмәт итә. 37 сәхнә әсәре язган Т. Гыйззәт ("Наемщик", "Ташкыннар", "Чаткылар" "Кандыр буе" һ. б.) барыннан да элек үзен зур драматург итеп таныта.

Татарстан АССРның (1939), РСФСРның (1940) атказанган сәнгать эшлеклесе.

Аның бронза-граниттан коелган әлеге бюсты Әгерҗе тимер юл вокзалы мәйданчыгына куелган (2003).

## Мөхәммәт Мәһдиев

(1930—1995)



Язучы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиев 1930 елның 1 декабрендә Татарстанның Арча районы Гөберчәк авылында туган. 1947 елда педагогия училищесын тәмамлаганнан соң Арча, Саба районы мәктәпләрендә укытучы булып эшли. 1950-54 елларда Балтика хәрби флотында хезмәт итә. 1959 елда, читтән торып укып, Казан дәүләт педагогия институтының тарих бүлеген тәмамлый. Казан дәүләт университеты каршында аспирантура тәмамлаганнан соң 1964 елны кандидатлык диссертациясе яклый. Өлкән укытучы, доцент булып эшли.

М. Мәһдиев иң элек әдәбиятчы һәм әдәби тәнкыйтьче буларак танылды. Язучы-прозаик буларак, 60 нчы елларның ахырында күренә башлый.

"Казан утлары"нда (1968 ел, 5 сан) "Без—кырык беренче ел балалары" исемле беренче повесте дөнья күрә.

Шуннан соң иҗат ителгән күләмле әсәрләре: "Фронтовиклар" (1972), "Ут чәчәге" (1980) романнары; "Кеше китә—җыры кала", "Торналар төшкән җирдә" (1978), "Исәнме, Кәшфи абый!" (1982) повестьлары һ. б.

Ул—РСФСРның атказанган культура работнигы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты.

Бюсты Арча үзәк мәйданына куелган (2004).

**Альфрет ӘБДРӘШИТОВ**





Чыганак: Казан утлары.- 2008.- № 6.

## СИБГАТ ХӘКИМ АРХИВЫ

Һәр язучының иҗат эшчәнлегендә берничә катламны аерып чыгарырга мөмкин. Барлык укучыларга да мәгълүм һәм һәркем таныша ала торган катлам—ул әлбәттә, аның басылып чыккан әсәрләре. Ә бит әдәби әсәрләр үзләре иң башта әдипнең күңелендә ярала. Язучының үзе генә белгән күңел кичерешләре, көтелмәгән ачышлары, ягъни башкалар хөкеменә бирелми торган эчке халәте, фикер-хис туу барышы икенче катламны тәшкил итә. Болардан тыш шулай ук иҗат лабораториясе белән турыдан-туры бәйле булган әдипнең уйлануларын, күзәтү-эзләнүләрен туплаган эш дәфтәрләре, көндәлекләре һәм әлбәттә инде әсәрләренең кәгазьдәге үсеш-үзгәреш өлешен чагылдырган кульязмалары—тагын аерым бер катламны барлыкка китерәләр. Соңгысы бербөтен буларак шәхси архивларның нигезен хасил итә. Иҗат манерасыннан, кульязма әдәбиятка субъектив мөнәсәбәттән чыгып язучыларның шәхси архив материаллары күләм һәм жанр ягыннан да төрле була. Мәсәлән, бер тип язучылар иҗат эшчәнлегендә көндәлекләр алып бару, куен дәфтәрләренә фикер, тормыш картиналарын теркәп баруны мөһим дип санасалар, икенчеләре моның кирәксез нәрсә булуын белдерәләр. Шулай ук шәхси архивларның күләме объектив сәбәпләр, аерым алганда, янгын, югалу һ. б. нәтиҗәсендә дә азаерга мөмкин. Әмма шунысы ачык: әдәбият фәне өчен шәхси архивлар—бик күп мәгълүмат бирә торган гаҗәеп кызыклы, мөһим чыганак.

Күренекле татар шагыйре Сибгат Хәкимнең иҗат итү үзенчәлекләрен, стиль алымнарын, идея-эстетик карашларын, аерым әсәрләренең туу тарихын өйрәнүдә дә шәхси архив материаллары нык ярдәм итә. Бу чыганаклар тулысынча "Казан" милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музее фондында саклана. Архивны бирегә 1993 елда шагыйрьнең хатыны Мөршидә Вилданова-Хәкимова тапшыра.

"С. Хәкимнең музейларга карашы үтә җитди һәм җаваплы, ә музей хезмәткәрләренә карата бик җылы һәм ихлас иде. Ул күп мәртәбәләр әдәби кичәләрдә чыгышлар ясады, шигырьләрен укыды, музейның гыйльми совет әгъзасы буларак һәрвакытта да үзенең төпле фикерен әйтә килде",—дип искә ала музей хезмәткәре И. Минһаҗева.

Архивның күләме чагыштырмача бик зур—4 492 саклау берәмлегеннән гыйбарәт. Аларны, гомуми характеристика биреп, түбәндәгечә төркемләргә мөмкин:

| № | Материал-чыганакларның эчтәлеге | Материал-чыганаклар кайсы елларга карый | Саклау берәмлекләре |
|---|---|---|---|
| 1. | Блокнотлар | 1949 -1986 | 13407/ 1-153 |
| 2. | Шигырьләр | 1938—1985 | 13407/154-180 |
| 3. | Поэмалар | 1948—1983 | 13407/ 181—193 |
| 4. | Тәрҗемәләр | 1940—1985 | 13407/ 194—238 |
| 5. | Публицистика | 1948—1980 | 13407/239-271 |
| 6. | Документлар, истәлекләр | 1939—1983 | 13407/272-346 |
| 7. | Фотографияләр | 1944—1986 | 13407/347-481 |
| 8. | Хатлар (үз кулы белән язылган) | 1943—1985 | 13407/482-518 |
| 9. | Язучылардан килгән хатлар | 1940-1986,1987 | 13407/519-1058 |
| 10. | Тәрҗемәчеләрдән килгән хатлар | 1950—1986 | 13407/ 1059—1465 |
| 11. | Башка республика язучыларыннан килгән хатлар | 1950—1984 | 13407/ 1466—1554 |
| 12. | Башкортстан язучыларыннан килгән хатлар | 1940—1985 | 13407/1555-1631 |
| 13. | Тәнкыйтьче, галим, мөхәррирләрдән килгән хатлар | 1949—1986 | 13407/ 1632—1694 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14. | Язучылар берлегеннән килгән хатлар | 1954-1985 | 13407/1695-1838 |
| 15. | Мәдәният эшлеклеләреннән килгән хатлар | 1950—1985 | 13407/ 1839—1994 |
| 16. | Дуслары, якташларыннан килгән хатлар | 1949—1985 | 13407/ 1995 -2270 |
| 17. | Туганнарыннан килгән хатлар | 1946—1980 | 13407/2271 -2365 |
| 18. | Фронтташ дусларыннан килгән хатлар | 1945—1985 | 13407/2366-2424 |
| 19. | Укучылардан килгән хатлар | 1950—1980 | 13407/2425-2649 |
| 20. | Мәктәп, мәдәни-мәгърифәт оешмаларыннан килгән хатлар | 1952—1985 | 13407/2650-2824 |
| 21. | Китап нәшриятларыннан килгән хатлар | 1950—1985 | 13407/ 2825—2968 |
| 22. | Газета редакцияләреннән килгән хатлар | 1941—1986 | 13407/2969-3158 |
| 23. | Хөкүмәт учреждениеләреннән килгән хатлар | 1954-1982 | 13407/3159-3307 |
| 24. | Чакыру, телеграммалар | 1950-1980 | 13407/ 3308—4002 |
| 25. | Шәхси әйберләре | | 13407/4003-4029 |
| 26. | Котлау адреслары, мактау грамоталары | 1975, 1981 | 13407/4030-4039 |
| 27. | С. Хәкимнең китаплары | 1938-1986,1991 | 13407/4040-4082 |
| 28. | С. Хәкимгә автографлары белән бүләк ителгән китаплар | 1939 -1986 | 13407/4083-4492 |

Таблицадан күренгәнчә, әлеге материаллар С. Хәкимнең дистә еллар дәвамындагы иҗат биографиясен һәм әдәби эшчәнлегенең ни дәрәҗәдә киеренке икәнлеген күзалларга ярдәм итә. Архив материаллары арасында әсәр кульязмалары, блокнотлар, хатларның булуы иҗат лабораториясен өйрәнүдә аеруча мөһим.

Язучыларның иҗат эшчәнлегендә көндәлекләр һәм әдәби әсәргә чимал булырдай язмалар үзләренә бер урын алып тора. Гадәттә аларны берләштереп куен дәфтәрләре дип тә атап йөртәләр, һәр әдипнең куен дәфтәрләренә үзенчә исем кушкан очраклар да билгеле. Мәсәлән, О. Бальзакта ул—"Сюжетлар, фрагментлар, фикерләр", Ә. Фәйзидә—"Идеяләр, сюжетлар", Г. Ахуновта—"Амбар кенәгәсе". Шул ук вакытта бу язмалар, иҗат процессы кебек үк, һәр авторның үзенә генә хас үзенчәлекләргә дә ия: мәгълүматны туплау рәвеше, күләме, хронологиясе һ. б. Алар тегe яки бу язучының иҗат барышында тоткан урыны, әһәмияте белән дә аерылып торалар.

Шәхси архив материалларыннан күренгәнчә, С. Хәкимнең кульязма мирасында кыйммәтле һәм әһәмиятле өлешен эш дәфтәрләре тәшкил итә. Алар, нигездә, төрле форматтагы блокнотлардан (куен дәфтәрләреннән) гыйбарәт. Күбесе 14х20; 14,5х20,5 форматлы. Шулай ук арада альбомнан кисеп ясалганнары да бар.

Эчтәлек ягыннан әлеге язма материалларны нинди жанрга кертеп карарга соң? Аларның беркадәр үрнәкләре С. Хәкимнең 1988 елда басылып чыккан "Яшә, борчулы җаным" җыентыгында тупланып бирелгән һәм әлеге хезмәтнең аннотациясендә "Бу китапка аның ... әдәби-публицистик язмалары һәм көндәлекләре җыеп бирелде"[1], дип язылган. Әмма бу язмаларны көндәлекләр дип атау бик үк дөреслеккә туры килми. Гомумән, әдәби язмаларда, тәнкыйть мәкаләләрендә "куен дәфтәре" белән "көндәлек"не тиңләштерү, бер үк мәгънәдә белдерү очраклары бар.

Көндәлекләр өчен язмаларның даталануы һәм даими рәвештә алып барылуы, аларның электәге түгел, ә агымдагы вакыйгалар һәм халәтләр белән бәйле булуы шарт. Көндәлекләрнең төп жанр үзенчәлеге вазифалары белән билгеләнә. Мәсәлән, О. Г. Егоров бу караштан "Дневники русских писателей XIX века"[2]исемле хезмәтендә көндәлекләрне өч төркемгә аерып күрсәтә. Беренчесенә авторларның психологик үзенчәлеген чагылдыручы язмалар керә. Мондый көндәлекләр яшь чакта языла башлый. Иң күпсанлы икенче төркемне исә язучыларның яшь вакыттан ук тотынган тормыш елъязмасы тәшкил итә. Өченче төркем—мондый язмаларга карт көнендә керешкән каләм ияләренең көндәлекләреннән гыйбарәт. Еш кына бары тик үзләре өчен генә язылганнарны да һәм киң матбугатка тәкъдим ителгәннәрен

[1] Хәким С. Яшә,борчулы җаным: Публицистика (1979—1986),Блокнотлар (1954—1986) / С. Хәким. Казан: Тат. кит. нәшр.,1988.—Б. 2.

[2] Егоров О.Г. Дневники русских писателей ХГХ века: исследование / О. Г. Егоров.—М.: Флинта: Наука,2002.—288с.





дә көндәлек дип атыйлар. Мәсәлән, "Идел" журналында Х. Туфанның 1963 елгы көндәлекләреннән китерелгән өзекләрне[3] укыгач, алар шагыйрьнең үзе өчен генә язылган сыман тоела. Тезислар формасындагы кыска-кыска җөмләләр, кайбер исемнәрнең хәрефләр белән генә бирелүе шул уйга этәрә. Ә менә Т. Миңнуллинның "Утырып уйлар уйладым" исемле китапларындагы төрле елларда көндәлек формасында язып барган тормыш, заман, кешеләр турындагы уйланулары, күзәтүләрен киң җәмәгатьчелек игътибарына да җиткерергә теләве ачык күренә. Автор аларны "әдәби эшкәртмичә" генә укучыга сөйләп бирәсе килә[4], дисә дә, җөмләләрнең төзек, фикерләрнең анык, вакыйгаларның эзлекле булуы язмаларның шулай да редакцияләнгәнлегендә шик тудырмый.

Дөрес, аерым жанрны тәшкил иткән көндәлекләргә хас сәхифәләрне С. Хәкимнең куен дәфтәрләрендә дә очратырга мөмкин. Кайберләрендәге язмалар периодик рәвештә даталанган һәм агымдагы вакыйгаларга бәйле рәвештә туган. Күп очракта аларның вакыты шагыйрьнең туган авылы Күлле-Кимегә кайткан яки төрле сәяхәттәге чаклары белән туры килә.

"С. Хәким иҗатына төп илһамны авылдан, туган җиреннән ала. Елның һәр җәендә, гадәттә сабан туйлары вакытына туры китереп, ул авылга кайта. Анда ул һәрвакыт көтеп алынган кадерле кунак,"—дип искә ала М. Шабаев үзенең истәлекләрендә.[5] Әйтик, шагыйрьнең 1959—1960 еллар белән искәртелгән бер блокнотында 1959 елның 11 июненнән 5 июленә кадәр даими даталанган язмалары урын алган. Биредә чордашларының портретлары, авыл тормышының үткәнен искә төшерү һәм бүгенгесе турында уйлану нәтиҗәсендә туган күңел кичерешләре, туган җир табигате белән ассоциатив бәйләнештә барлыкка килгән фикерләр дә теркәлгән. Алар әдипнең кайбер шигырьләренең башлангыч уй-нияте, шигъри фикернең тууына сәбәп булган этәргечләр турында да сөйли. Мәсәлән, шундыйларның берсе: "Җирдән бик күп давыллар узды. Октябрь давылы, Гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы һ. б. Безнең ил тормышында күп үзгәрешләр булып узды. Давыл чәчәкләре күп нәрсәне искә төшерә, уйландыра, тормышның гел көрәштән торуының символлары алар. Давылдан соң тормышның яхшыруына халыкның өмете зур. 30. 06. 59"[6]. Халык романтикасы белән сугарылган сары чәчәкләр белән очрашу шагыйрь йөрәгендә тирән эз калдыра һәм сугыш, тынычлык турындагы "Давыл чәчәкләре" шигырен язуга этәргеч бирә:

*...Җир өстеннән күпме давыл узды,*
*Бөтерелде күпме өермә...*
*Утыра шомлы давыл чәчәкләре,*
*Курkам никтер якын килергә...*[7]

Әмма алда әйтелгәнчә әлеге конкрет мисалларга таянып, С. Хәкимнең куен дәфтәрләрен эчтәлек ягыннан көндәлекләргә кертеп карау дөрес булмас. Бу очракта, аларны (көндәлек) эш язмалары дисәк, отышлы шикелле. Чөнки куен дәфтәрләрендәге язмаларның күбесе шигъри вариантлар рәвешендә, шагыйрьнең шигъри текст өстендә эшләү барышын чагылдыра, яисә иҗат процессы өчен чимал булырдай вакыйга—күзәтүләр, образ-сурәтләр, детальләрдән гыйбарәт. Поэмалар иҗат итү нияте туган очракта, ул аерым дәфтәрләр башлаган һәм анда язылачак әсәргә кагылышлы материалларны, уй-фикерләрен, җентекле планнарын, беренче сызымнарын теркәп барган.

Шагыйрьнең иҗат стиле хакында куен дәфтәрләре дә күп мәгълүмат җиткерәләр. С. Хәкимнең шәхси архивында саклaнган куен дәфтәрләре дә үзенчәлекләргә ия. Андагы язмаларның күп очракта, билгеле бер тәртиптә булмыйча, аерым-аерым

[3] Туфан Х. "Көнем өчен түгел,илем өчен..." / Х.Туфан // Идел.—2000.—№ 8.—Б. 60—63.

[4] Миңнуллин Т. Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр / Т. Миңнуллин—Казан: Тат. кит. нәшр.,1997.—Б. 3.

[5] Таныш өянкеләр: С. Хәким турында истәлекләр. Төзүчеләре: М. Вилданова-Хәкимова, Р. Хәкимов.—Казан: Тат. кит. нәшр.,1996.—Б. 180.

[6] Шагыйрьнең шәхси архивыннан.

[7] Хәким С. Шигырьләр / С. Хәким.—Казан: Тат. кит. нәшр.,1976.—Б. 228.

урыннарда теркәлүе әдипнең аңына килгән яңа уй-фикерләрне, детальләрне тизрәк кәгазьгә төшереп калдыруын күрсәтә. Чөнки әдип аңындагы иҗат барышы катлаулы, үзгәрүчән һәм ул хәтердә тулы, бербөтен килеш сакланмаска да мөмкин. Шуна күрә куен дәфтәре хәтергә ярдәмче роль үти. С. Хәким дә күзәтүләрен, тәэсир иткән вакыйгаларны үзенә генә аңлаешлы рәвештә берничә сүз яки җөмлә белән теркәп барган. Алар, шагыйрь өчен күп нәрсә турында сөйләсә дә, читтән укучыга беренче карашка эзлекле мәгълүмат бирми.

Шул ук вакытта шагыйрь үзенең язмаларында иркен ориентлашкан булса кирәк. Кайчакта билгеле бер өлешләрне аерып алган, отышлы урыннарны "+"тамгасы белән билгеләгән. Аерым блокнотларда билгеле бер эзлеклелекне дә күрергә мөмкин: иң элек язылачак әсәрләрнең уйланмалары теркәлә, соңыннан шигъри текст буларак җанланганнарының мөстәкыйль, бербөтен хәленә килгәнчегә кадәрге үсеш-үзгәреше чагылыш таба.

Эш дәфтәрләрен С. Хәким бөтен иҗади гомере дәвамында алып барган. Аларда әдипнең иҗат юлы, рухи үсеше күренә. Иҗат өчен аларның мөһим чыганак булып хезмәт итүләре гаҗәп түгел, чөнки бу язмаларда әйләнә-тирәгә мөнәсәбәт, тормышның эченә үтеп керү дә чагыла.

Кулъязмалар—иҗат лабораториясен иң тулы чагылдырган материаллар. Болар—әсәрләрнең караламалары һәм чиста нөсхәләре, басмаханәләргә тәкъдим ителәсе текстлар.

Әсәр бинасын әдип сүзләрдән кора. Сүз әдәби әсәрнең төзү материалы булып хезмәт итә. Әдәби әсәрдә һәр күренеште тик үз сүзе белән, бары тик шул предметны, билге, гамәлне анлата торган тәгъбир ярдәмендә генә белдерергә мөмкин. Моның өчен әдиптән телне бар күләмендә, бөтен тирәнлегендә белү сорала[8]. С. Хәкимгә дә шигырьләрендә кирәкле сүз куллану, алыштыргысыз, урынлы гыйбарә уйлап табу өчен шактый эзләнергә, тырышырга, телнең мәгънә төсмерләрен белеп, аңлап эш итәргә туры килгән. Моның шулай булуын архивында сакланып калган күпсанлы кулъязмалар раслый. Бу чыганаклар һәм андагы үзгәреш-төзәтмәләр шагыйрьнең шигъри сүз өстендәге эшчәнлеген тулырак өйрәнергә ярдәм итә.

Әдипнең архивындагы кулъязма чыганаклар белән таныша башлауга, игътибарны иң элек эре хәрефләр белән өстән аска таба бераз авышрак язылган тезмәләр, җөмләләр җәлеп итә. Гүя, шигъри әсәрләрендәге кебек, хисләр кәгазь битләренә сыеша алмый. Шул ук вакытта җөмләләр кыска, тирән мәгънә сыйдырганнар, шагыйрьнең иң кирәклесен генә әйтергә теләгәне сизелеп тора.

С. Хәким иҗади эшчәнлегенең кулъязмалар этабы, бик сирәк очракларны искә алмаганда, ике баскычтан: каралама һәм чиста тексттан тора. Аның кулъязмалары төзәтмәләр белән чагыштырмача артык чуарланмаган. Беренче карашка шулай, әмма бу шагыйрьнең шигъри бөтенлеккә, төгәллеккә ирешү юлында үзгәреш-төзәтмәләр аз кертүе турында сөйләми. Чөнки, караламалардан күренгәнчә, С. Хәким текст өстендә эшләүгә караганда, аны яңадан күчереп язуны кулайрак тапкан. Текст азрак сызгалана башлауга, С. Хәким чираттагы үзгәрешен кертү өчен, алда язылганнарны тулысынча кабат кәгазьгә төшергән. Шигъри әсәрләрен язганда, ул аерым юл, строфалардагы төзәтмәләр белән генә чикләнеп калмыйча, тулы бер эзлеклелектән, бәйләнештән чыгып эш итә.

Теге яки бу язучының иҗат лабораториясенә үтеп керүдә хатлар, шулай ук, көндәлекләр, (көндәлек) эш язмалары һәм кулъязмалар дәрәҗәсендә, ышанычлы материаллар. Чөнки эпистоляр язмаларда шәхес тулысынча ачыла.

Әдип—хатларында үз табигыйлегендә кала: үзеннән көчлерәк тә була алмый, үзеннән кечерәк тә булып күренми—ничек бар, шулай.

Гадәттә, әдипләрнең үз куллары белән язган хатлары шәхси архивларында аз сакланып кала. Бу С. Хәкимдә дә ачык күренә. Бирегә үзенә юлланган хатлар белән чагыштырганда, аларның саны күпкә аз. Чынлыкта исә шагыйрь иҗатташ дуслары, бигрәк тә яшь язучылар, башка сәнгать әһелләре белән аралашып, хат алышып яшәгән. Соңгы елларда аларның кайберләре адресатларының истәлекләрендә, яисә

[8] Хатипов Ф. М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма / Ф. М. Хатипов. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 306.





вакытлы матбугатта дөнья күрде. Әйтик, аның артист А. Арслановка[9] һәм композитор С. Садыйковага[10] юллаган хатлары.

Шамил Маннапов аның хатлары турында хаклы рәвештә : "Эре, ачык хәрефләр, кәгазь битен тарсынгандай, аска таба шуышканнар. Сүзгә саран, фикергә бай, кысылган пружина сыман тыгыз җөмләләр. Иң кирәклесен генә әйтергә ниятләү сизелеп тора. Бу хатларны язган кулны башкалар белән бутау һич мөмкин түгел"—дигән нәтиҗә чыгара[11].

Хатлар С. Хәкимнең олы җанлы һәм тынгысыз шәхесен бик тә дөрес чагылдыра. Бу эпистоляр язмаларда әдипнең әдәби-эстетик карашлары, шигъри осталыгын һәм иҗат барышын чагылдырган фикерләре дә урын алган. Мәсәлән, түбәндәге өзектә шагыйрь каләмена бер иш әсәрләрнең чагыштырмача җиңелрәк бирелүе, ә кайберләренең исә күп көч, озак эзләнүләр таләп итүе күренә: "Айрат! Сезгә әйткән шигырьне җибәрәм, басылмаган, яңа. Бик яратып яздым, бер көндә яздым, күтәренке рух белән. Аннан соң Муса турында бер шигырьгә тотынган идем, монысы кебек тиз генә язып ташларга дип. Юк, энем, һәрвакыт алай булмый икән. Бер атна маташтым, кул селтәдем... Табылса табыла, табылмаса берни эшләп булмый, хет ярыл... 08. 10.1980"[12].

С. Хәким иҗатының үзе исән вакытта ук укучылар тарафыннан җылы кабул ителүе болай да күпләргә мәгълүм. Ә менә шул турыда замандашларының, аеруча ул вакытларда әдәбиятка яңа аяк баскан яшь язучыларга шагыйрьнең ни рәвешле тәэсир итүе, әсәрләренең ничек кабул ителүен хатлардан укып танышу С. Хәким шигърияатенең тәэсир көче, халыкчанлыгы хакында тагын да җитдирәк уйланырга этәрә. Әйтик, шагыйрьә С. Сөләйманованың әдипкә юллаган хаты. Бирәдә ул бер әсәр аша гына да С. Хәким иҗатының поэтик көчен югары бәяли:

"Казан утлары"нда чыккан көтүче турындагы шигырь (С. Хәкимнең авылдашы Фоат Әхмәтшинга багышлап язылган "*** Кайта ул көтү алдыннан" (1976) шигыре.—Р. М.) хакында күптән язарга йөрим сезгә... Соңгы елларда укыган шигырьләр арасында миңа иң ошаган шигырь ул. Үзе гади, үзе бөтен дөньяны эченә алган. Кечкенә авыл, сугыш, җиңү, тынычлык—барысы да шунда сыйган. Шундый шигырьләр күбрәк булса, хәзерге татар поэзиясе көчле булыр иде... 03. 05. 1977"[13].

Хатлар С. Хәкимнең әдәби алмаш өчен борчылып яшәвен, өметле яшь язучыларга рухи ярдәм итүе, игътибарлы булуын тагын бер кат раслыйлар. Аның шәхси архивында Р. Гәрәй, Г. Афзал, Г. Рәхим, М. Хәсән, Ә. Баян[14] һ. б. яшь язучылардан киңәш яки җибәрелгән әсәрләрен күзәтеп чыгуны сорап язган хатлар шактый. Шагыйрьнең күпчелек җавап хатлары рецензия жанрын хәтерләтәләр. Адресатның аерым әсәре яки шигырьләр бәйләменә карата уңай яки житешсез якларны, артык сузмыйча, конкрет фикерләр аша житкерә. Аларда шулай ук үз поэтикасын характерлаган, яисә шул чор поэзиясе нинди булырга тиеш дигән карашлары, иҗат принциплары чагыла: "заман ритмын тапкан", "гомумиләштерү көченә ия ", "шагыйрьгә зур дөнья кирәк", "халыкчан" кебек фикерләрне еш очратырга мөмкин.

Шулай итеп, архив материаллары С. Хәкимнең шәхесе, иҗат лабораториясенең үзенчәлекләрен, әдәби осталыгын, иҗади уй-ниятләренең сәбәпләрен тулырак өйрәнергә мөмкинлек бирә. Шулай ук чыганаклар әдипнең тормышындагы мөһим тарихи эпизодларны аңларга, татар әдәбиятының шагыйрь иҗат иткән дәвердәге тарихын, шул чорның әдәби, мәдәни мохитен күзалларга да ярдәм булыша.

**Рамил МОЗАФФАРОВ,**
*Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

[9] Арсланов А. Сәнгать әһелләрен үз күрде / А. Арсланов // Шәһри Казан. – 2001. – 21 декабрь.

[10] Гадел Ә. Мәдәниятебезнең ике бөркете ( Сибгат Хәкимнең Сара Садыйковага хатлары) / Ә. Гадел // Шәһри Казан. – 2006. – 9 ноябрь.

[11] Маннапов Ш. Хатларда шагыйрь йөрәге / Ш. Маннапов // Таныш өянкеләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1996. – 32 б.

[12] А. Арсланов. Сәнгать әһелләрен үз күрде // Шәһри Казан. – 2001. – 21 декабрь.

[13] Шагыйрьнең шәхси архивыннан.

[14] "Казан" ММҮ фонды. – 13407/847, 13407/891, 13407/893.